Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2019 елның 11 феврале № 93

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 февралендәге 83 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советының муниципаль хезмәткәрләре һәм аларның вазыйфаи хәлләренә яисә аларның хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, гамәлгә ашыру (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашырудан кергән акчаларны кабул итүне хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи хәлләренә яисә алар тарафыннан хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, гамәлгә ашыру (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашырудан кергән акчаларны күчерү турындагы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 февралендәге 83 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль вазыйфаларын биләүче затлар һәм Олы Салтык авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи хәлләренә яисә алар тарафыннан хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу, бүләк тапшыру һәм бәяләү, аны гамәлгә ашыру (сатып алу) һәм аны гамәлгә ашырудан кергән

акчаларны кабул итү турында хәбәр итү тәртибе”  нигезләмәсенә  үзгәреш кертергә:

1) Нигезләмәнең 2 пунктындагы икенче абзацында «хәлиткеч тавыш хокукы белән» сүзләрен "хәлиткеч тавыш хокукы белән даими (штат) нигездә , комиссиядә эшләүче " сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендлар аша халыкка белдерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 нче йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71 нче йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Мәрәтхуҗа авылы,Ленин урамы, 61 нче йорт, шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Салтык  авыл җирлеге Советы рәисе  Х.Х. Ибатов